ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 3-74-77; e-mail: Otar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

«22» декабрь 2017 ел — №35

### Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере үрнәген раслау турында

Эш башкаруны тәртипкә салу, Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитеты документларын ышанычлы тәңгәлләштерүне тәэмин итү максатларында, Мамадыш районы прокурорының дәүләт символлары турындагы закон бозуларны бетерү турындагы 15 августындагы № 02-08-03-2017 тәкъдиме, Мамадыш муниципаль районы Советының 2017 елның 13 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге гербын куллану турында» № 6-19 карары нигезендә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере оттискын расларга.(1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 22 декабрендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегендә мөһерләрне һәм штампларны исәпкә алу, әзерләү, куллану, саклау һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- мөһерләрне, штампларны һәм фирма бланкларын куллану;
- аларны куллануны, тиешле саклауны һәм саклануын контрольдә тоту.

Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә..

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /Миннекаев Х.М./

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере оттискы

